СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 нюленнән бирле чыга. | №31 (7214) | 16 март, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

«Сез Совет Социалистик Республикалар Союзының тигез хокуклы суверен республикаларның яңартылган федерациясе—теләсә нинди милләт кешесенең хокуклары һәм ирекләре тулысынча гарантияләнәчәк федерация сыйфатында саклап калырга кирәк дип саныйсызмы?»

(Бөтенсоюз референдумы бюллетены соравыннан).

## 17 март—Бөтенсоюз референдумы көне

# Урманчылар безнең фикердә

ССР Союзын саклау буенча халыктан сорау уздыруга хәзерлек мәсьәләсе бу көннәрдә, табигый ки, хезмәт коллективлары белән очрашуларның үзәгендә тора. Хәзер урман эшчеләре дә, бөтен халык кебек үк, политика белән кызыксыналар. Цехларда һәм подразделениеләрдә очрашу, сөйләшүләр барышында соңгы моментта бу тема игътибар үзәгендә тора.

Бу мәсьәлә буенча участокларда махсус җыелышлар да үткәрелде. Аларны партком карары нигезендә оештырдык. Җыелышларда партком членнары коммунистларга һәм урманчыларга агымдагы момент, референдумны үткәрүнең зарурилыгын аңлаттылар. Коммунистларның һәм партиясезләрнең дә бу мәсьәләдә фикере бер үк төрле: республикалар союзыннан торган илебезнең бердәмлеген киләчәктә дә саклау кирәк. Аны саклау өчен илебезнең күпме халкы корбан булган, ярым ач-ялангач хәлдә хәрабәләрдән күтәргән. Бүген шундый корбаннар исәбенә яуланган иминлеккә каршы чыгучы, милләтләр арасында үзара коткы, дошманлык хисе таратучылар табыла. Бу уңайдан бер нәрсәне генә әйтәсе килә: аерылырга омтылучылар теләсә кайда булса да, милләтче-шовинист. Хәер, шөкер, безнең хуҗалыкта андый кешеләр юк, төрле милләт вәкилләре иңгә-иң куеп, бер-берсенә ышанып, таянып, дус һәм тату яшиләр, эшлиләр. Җыелышларда милләтчеләрнең бу алымнарын гаепләп чыгалар.

Шуңа күрә референдум көнендә урман эшчеләренең куелган сорауга уңай җавап бирәчәгенә, «әйе» диячәгенә ышанычы зур партия оешмасының.

**Е. АЛЕКСАНДРОВА,**
урман промышленносте хуҗалыгының партия оешмасы секретаре.

# Тарихи безнең бергәлек

Бүгенге көндә илдә килеп туган хәлгә, референдумга җиңелчә караш өлкән буыннар күңелендә аеруча борчу тудыра. Мин —Октябрь яшьтәше, моңдый киеренке моментта үткән тарихыбызга күз салам һәм еш уйланам. Әтибабаларыбыз халыклар арасында дуслыкның асылын яхшы аңлаганнар һәм берләшүгә омтылганнар. Бөек Ватан сугышы чорында һәм Тын океан флотында хезмәт иткәндә без төрле милләт вәкилләре уртак максатны күздә тоттык, шатлык һәм кайгыларыбыз да уртак иде.

Бүгенге хәлебезне мин үзе утырган ботакны үзе кисүче кеше кебегрәк итеп күзаллыйм. Халык арасында һәм шул исәптән матбугатта да, Татарстан мөстәкыйль килеш алдынгы илләр рәтенә чыга ала дигән фикер белдерүчеләр бар. Моңа алшарт итеп нефть һәм газ кебек чималлар булуын китерәләр. Ләкин бу ялгыш фикер. Тормыш хакыйкате бөтенләй икенче, аерылып уңышка ирешеп булмый. Бүгенге шартларда бу бигрәк тә, чөнки Татарстан, мәгълүм булганча, суверенитет турында декларация кабул итте. Ул болай да экономик һәм политик яктан мөстәкыйль республика инде. СССР составында союздаш республика хокукында башкалар белән тыгыз элемтәдә һәм булышлыгы белән ТССР бүгенге кыен хәленнән чыга, экономикасын интенсив үстерә, халыкның тормыш хәлен яхшырта, сәяси хәлне стабильләштерә ала.

Хәзер яңа Союз договоры проекты басылып чыкты. Анда һәр республиканың үсеш юллары чагылыш тапкан. Анда шулай ук бердәм, кулга-кул тотынып эшләп Ватаныбызны баету, ныгыту идеясе алга сөрелгән. Бу кадәренә бәйнәләп тукталып торасы түгел иде дә, ләкин Союзны таркату, һәр милләтне үзенә бүленү турында һәр республика, өлкәдә коткы салучылар, ачыктан-ачык шуңа өндәүчеләр шактый табыла. Моңдый шартларда без, ягъни дистәләрчә еллар сакланган, тормышта үзенең көчен, өстенлеген исбатлаган бердәмлек яклы кешеләр, кем әйтмешли, авыз ябып торырга тиеш түгелләр. Шуңа күрә мин дә, сүз ирегеннән файдаланып, барлык райондашларымны референдум көнендә яңартылган, һәр милләтнең ирекле гарантияләнгән ССР Союзын яклап тавыш бирергә чакырам. Бары суверен республикалар федерациясе бергәлеге генә илне экономик һәм политик кризис хәленнән чыгара алуын исегездә нык тотыгыз.

**М. РӘҖӘПОВ,**
сугыш һәм хезмәт ветераны.
Норлат шәһәре.



Буран. Урамда юлга салган карны чистартып өзлексез бульдозер йөри. Әмма тискәре җил чистартылган юлны янәдән кар белән сылап куя. Шунда ук йөк машинасы кереп чумган, ике кеше тәгәрмәчләрне казу белән мәшгуль. Аларга көрәкле өченче кеше килеп кушыла. Югыйсә, аның ярдәменә монда өметләнмәделәр дә. Ул бит ялыктыргыч эш көнен төгәлләп өенә кайтып килүче. Менә шундый ул—Камил Сәгыйрь улы Зарипов. Эшчән, янәшәсендәгеләр белән исәпләшүчән, аралашучан, авылдашларының ихтирамын казанган кеше. Армиядән соң туган авылында калган иде, шуннан бирле савым көтүендә терлекче булып эшли. «Сыерның сөте—телендә», —дигән әйтемне ул бер дә исеннән чыгармый. Сыерларның тамагы тук, сөте мул булсын өчен үз-үзен аямыйча эшли. Көн ахырына таба куллары һәм аяклары талчыгудан гүли башлый, әмма Камил Сәгыйрович канәгатьлек белән елмая: урамда буран булса да, фермада тыныч, чылбырлар зеңгелдәве генә ишетелә—сыерлар силос, салам, чөгендер түбе ашыйлар, күшиләр. Урамдагы җил һәм буран аларга әллә бар, әллә юк шунда.

Рәсемдә: «Чишмә» колхозы терлекчесе К. С. Зарипов.

## Бердәм булсак—җиңә алмаслар

Бөтенсоюз референдумын үткәрү көне якынлаша. Мин авылда яшәүче гади кеше генә булсам да, бер нәрсәне ачык әйтә алам: безнең көч—бердәмлектә. Моны күренекле педагог К. Д. Ушинскийның һәркемгә мәгълүм хикәясе мисалында ачыклап узасым килә. Бер карт бервакыт улларын чакырып алган, себерке биргән һәм сындырырга боерган. Тегеләр, никадәр тырышмасын, берни эшли алмыйлар икән. Шуннан карт аларга себеркене сүтәргә һәм чыбыкларын аерым-аерым сындырырга рөхсәт иткән. Бу юлы малайлар кушканны бик тиз үтәп чыкканнар. «Менә күрдегезме,—дигән карт,—аерым-аерым булганда теләсә кемне җиңеп була, бергәне—һич юк!»

Бу картның сүзләре тулаем илебез язмышына да тәңгәл килә: халыклар, республикалар бердәм икән, дәүләтебез дә көчле булачак. Милләтләр арасында тынычлык, иптәшлек һәм тигезлек илнең политик һәм экономик проблемаларын хәл итүгә дә ныклы нигез булып тора.

Кыскасы, әйтәсе килгән фикерем шул: ТССРның дәүләт суверенитетын саклаган хәлдә тигез хокуклы Союзда тору яклы мин.

**Т. АЛЯКИМОВА.**
Түбән Норлат авылы.

## Пайчылар сөйләште

14 мартта пайчылар җыелышы булып үтте. Җыелыш оештыру мәсьәләсен карады. Райпо идарәсе рәисе М. М. Сафин рәис вазифаларыннан азат ителде. Идарә рәисе итеп, элек аның урынбасары булып эшләгән, Һади Харисович Садыйков сайланды. Рәис урынбасарына пайчылар бертавыштан элек коопродторг директоры булып эшләгән Фәрит Нилович Гобәйдуллинны сайладылар.

Җыелышта райпо идарәсе рәисе Һ. Х. Садыйков «Райпоның 1990 елгы эш йомгаклары һәм район халкына сәүдә хезмәте күрсәтүне яхшырту буенча агымдагы ел бурычлары турында»гы доклад белән чыкты.

Ревизия комиссиясе эше турындагы отчетны аның рәисе Р. Х. Яруллина ясады.

Җыелыштагылар 1990 елга балансны раслау, табышны бүлү проекты турындагы мәсьәләне дә тикшерделәр. Аның буенча райпоның баш бухгалтеры Б. А. Кузьмина чыгышы тыңланды.

Пайчылар тикшерүенә пайга һәм аңа керү бәяләренә үзгәрешләр кертелү, рәис, аның урынбасары, баш бухгалтерга хезмәт хакын раслау турындагы мәсьәләләр кертелгән иде.

Аннан соң доклад буенча фикер алышулар башланды. Анда чыгыш ясаучылар халыкны кирәк товарлар белән тәэмин итү, талоннарны реализацияләүдә туган кыенлыкларга тукталдылар. Пайчылар гомумән алганда районның узган елдагы эшен канәгатьләнерлек дип таптылар.

Җыелыш эшендә район Советы рәисе, КПСС райкомының беренче секретаре Х.Х. Морадыймов һәм Татпотребсоюз идарәсе рәисе Р. Ф. Сафиуллин катнашты һәм иптәш Сафиуллин речь белән чыкты. Ул, гомумән алганда, халыкны кирәкле товарлар белән тәэмин итүдә килеп туган хәлгә тукталды.

Җыелыш тикшерелгән мәсьәләләр буенча тиешле карар кабул итте.

## Бүгенге санда

*БЕЗ СОЮЗНЫ САКЛАП КАЛУ ЯКЛЫ

*БӘЙРӘМ КОТЛЫ БУЛСЫН

*КЕШЕ ИГЪТИБАР СОРЫЙ

## Тынычлык телибез

РСФСР Югары Советы рәисе Б. Н. Ельцинның 19 февральдә үзәк телевидение аша ясаган чыгышын күңелдә әрнү хисе белән тыңлаган идек. Ул илебезне тынычлыкка түгел, ызгышларга өнди. Ельцин СССР халык депутатлары сайлап куйган Президентка яный, аны власттан алырга чакыра. Бу ССР Союзын таркату политикасы һәм без моңа юл куя алмыйбыз.

Юк, без башка республикалар белән булган элемтәне югалтырга һәм аерым яшәргә теләмибез. Шуңа күрә 1991 елның 17 мартында үткәреләчәк референдумда Союзны саклап калу турында тавыш бирәбез.

**М. МӨХӘММӘТШИНА,**
**Р. ҖИҺАНШИНА,**
**Л. ОБУХОВИЧ.**
Норлат шәһәре.

# КИЛӘЧӘГЕБЕЗ ХАКЫНА

Мин политиканы һәрвакыт ирләр эше санап килдем. Әмма вакыты килде, бу өлкәдә хатын-кызлар да үзләрен актив күрсәтә башладылар. Безнең яңа лидер Фәүзия Бәйрәмованың исеме күпләрнең теленә-тешенә керде. Әйе, беренче вакытларда ул мине дә халык турында кайгыртучанлыгы белән җәлеп итте, үзенә ышанычы уялады. Аның тел, традицияләр, хокуклар турында чыгышлары берәүне дә битараф калдырмады. Татар халкы, шул исәптә мин дә, аны безнең Сөембикә дип атый башлады. Ләкин тора-бара саен бу хатынның йөзе ачыклана башлады.

Бу хакта сөйләгәндә мин аны Ельцин белән чагыштырып карыйм. Алар икесе дә арзан популярлыкка омтылалар, халык турында кайгыртучанлык күрсәткән булып кыланалар, чынында исә илне гражданнар сугышына этәрәләр. Ярый, без Союздан чыктык, суверен дәүләт булдык, ди. Барлык постларны татар телен белүчеләр били: халык мәгарифендә, хезмәт күрсәтүдә, сәүдәдә һәм сәламәтлек өлкәсендә дә шулай. Ә рус телендә сөйләшүче халык ни эшләргә тиеш? Аңа физик, хезмәт кенә каламы? Кеше хокукларын яклау шушы буламы? Бу милли принцип нигезендә халыкны дискриминацияләүгә кермиме? Әлбәттә, аларга да татар телен өйрәнергә кирәк диючеләр табылуы мөмкин. Руслар белән бер хәл әле, ә башка милләтләр?! Алар туган телләреннән тыш үз вакытында русчаны өйрәнергә тиеш булдылар, хәзер исә алардан татарчаны белү дә таләп ителә килеп чыга. Моны мин гадел саный алмыйм. Һәр халык үз туган телендә, ә берберсе белән аралашу өчен русча сөйләшсен. Бу әлеге телнең чуваш яки татар теленнән яхшы дигән сүздән чыгып түгел, шулай килеп туган тарихи хәлдән, чөнки халыкның күпчелеге рус телен белә һәм аралаша. Бу мәсьәләнең бер ягы. Икенчедән, русларга карата безнең политика ирекле яки ирексез рәвештә Татарстаннан читтә яшәүче безнең кардәшләребезгә дә кагыла.

Минем 8 балам, алар үсеп җитте, өйләнештеләр һәм таралдылар. Киленнәрем һәм кияүләрем арасында татарлардан тыш руслар, украиннар, казахлар, үзбәк һәм еврей бар. Шуңа күрә, намаз укырга керешкәч, алладан җиргә тынычлык сорыйм: балаларым һәм оныкларым берберсенә каршы сугышка чыкмаса иде. Катнаш гаиләләр аеруча авыр чор кичерәләр бит бүген. Кем булырга? Кем ягына авышырга? Мондый сораулар күңелне даими борчып тора хәзер. Үз әнием дә шул милләттән булган татарларны якларгамы, әллә башка милләт вәкилләре булган килен-кияүләрне якларгамы? Безнең күңелләргә шундый курку, коткы салган кешеләрне ничек яклыйсың ди инде. Юк, Фәүзия, безгә синең арттан бару ярамый, ул илебезгә, халкыбызга каршы бару дигән сүз. Шуңа күрә, 17 мартта без «Әйе» диячәкбез. Балаларыбыз, киләчәк буыннар хакына.

**Ф. ИБРАҺИМОВА.**
Норлат шәһәре.

# Чираттагы киңәшмә үтте

13 мартта СССР референдумын үткәрү буенча чираттагы киңәшмә булды. Анда участок комиссияләре рәисләре, секретарьлары, авыл Советы башкарма комитеты рәисләре, партия оешмалары секретарьлары, финанс органнары, элемтә, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы, энергия белән тәэмин итү, хокук саклау органнары җитәкчеләре, район Советы президиумы, район Советы башкарма комитеты һәм партия райкомының җаваплы работниклары катнашты.

Киңәшмәдә округ комиссиясе эше турында белдерү белән комиссиясе рәисе Н. Х. Абдуллин чыкты. Район Советы рәисе урынбасары Т. А. Назарова СССР референдумын үткәрүгә әзерлекнең йомгаклау этабында практик эшчәнлек турында чыгыш ясады.

Киңәшмәдә КПСС райкомының оештыру-партия эше һәм башлангыч партоешмаларның эшчәнлеген яңарту буенча комиссия рәисе урынбасары Ф. Ш. Галимов СССР референдумында КПСС райкомы вәкилләренең ролен ачыклады. Аннары халык депутатларының район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары А. И. Газизуллин, район финанс бүлеге мөдире Р. Г. Билалов, элемтә узелы начальнигы Р. Э. Гайфетдинов, автотранспорт предприятиесе начальнигы И. М. Вәлиев, җәмәгать туклануы предприятиеләре директоры С. У. Кашапова, район эчке эшләр бүлеге начальнигы урынбасары Х. З. Зарифуллин, кино челтәре директоры Р. М. Низамов иптәшләрнең СССР референдумына әзерлек буенча белдерүләре тыңланды.

Киңәшмәдә катнашучылар Татарстан республикасының Югары Советы президиумына, республика халык депутатларына Мөрәҗәгать кабул иттеләр. Анда алар Татарстан ССР Югары Советының РСФСР референдумында катнашудан баш тартуын бердәм хуплауларын белдерделәр. Соңыннан практик занятие үткәрелде.

Киңәшмә эшендә Октябрь район Советы рәисе КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов катнашты.

# БЕРДӘМЛЕККӘ ЧАКЫРАМ

Мин китапханәче булып эшлим. Билгеле булганча, бу бина бервакытта да буш булмый диярлек. Кичен җыелышкан яшьләр белән дөнья хәлләре турында сөйләшеп китәбез. Фикерләр төрле була инде ул. Менә соңгы айларның яңалыкларыннан 17 мартта булачак Бөтенсоюз референдумы хакында бәхәсләр булгалап ала. Кайберәүләр «Референдум нәрсә бирер икән?» дип шикләнүләрен белдерәләр.

Ә мин үзем яңартылган республикаларның тигез хокуклы Союзын яклап тавыш бирәчәкмен.

Хәзерге көндә Ватаныбыз авыр хәлдә әле, аның киләчәге дә ачыкланып бетмәгән. Җитәкчеләрнең дә кайберләрен тәнкыйтьләп ташлыйбыз, кайберләрен хуплыйбыз, илдәге хәлләргә карап уфтанабыз, көенәбез. Ничек кенә булса да болар вакытлы хәлләр, вакытлы кыенлыклар диеп уйлыйм мин.

Әйдәгез, районташларым, авылдашларым, барыбыз да тупланганлык күрсәтик, 17 март көнне Союзны яклап «әйе» дип җавап бирик. Татарстанның киләчәге дә бердәмлектә, милләтләр арасындагы тигезлектә диеп уйлыйм мин.

**Ч. РӘҖӘПОВА.**
Киекле авылы.

# Сүздән эшкә күчәргә вакыт

Газетага гомере язганым юк иде. Х. Әхмәтовның «Көч бердәмлектәме?» мәкаләсен укымасам, әле дә моңа алынмаган булыр идем. Үзем язмасам да, матбугатны даими күзәтәм. Дөресен әйтергә кирәк, элек Ватан язмышы турында борчылмый идем мин. Тел осталары кычкырырлар-кычкырырлар да туктарлар, халык аңсыз түгел, нәрсәнең нәрсәгә яраганына үзе төшенер дия торган идем. Алай түгел икән, минем мондый өметләрем акланмады. Безнең районда да халык активлашты. «Халыклар дуслыгы» дигән сүз тезмәсе төрле кешенең күңелендә төрлечә яңгырый хәзер. Шуңа күрә дәшми калырга һәм көтәргә мөмкин түгел, һәркем Ватанны яклап үз сүзен әйтергә тиеш. Мин үзем партиясез, әмма КПСС политикасы белән килешәм. Бу уңайдан шуны әйтергә телим: бер начар терлек көтүне пычраткан кебек аерым коммунистларның, лидер булсалар да, үз-үзләрен тотышы тулаем партиягә пычрак яга алмый.

Чын коммунистлар—үз идеяләренә бирелгән изге кешеләр. Мин мондый яңгыравык сүзләрне әйтүдән курыкмыйм. Без өлкән буыннар вәкилләре хәтерендә моны дәлилләргә мисаллар аз булмады. Ачлык елларында, сугыш, чорында алар соңгы кисәк икмәккә кадәр бүлештеләр. Алар беренчеләр булып атакага күтәрелделәр, без—партиясезләр өчен үрнәк булдылар. Коммунист сүзе һәрчак безнең күңелләрдә әнә шундый кешеләрне гәүдәләндерде.

Инде Союз турында берничә сүз әйтеп үтим. Аның бердәмлеген сакларга кирәк. Безнең балаларыбыз һәм оныкларыбыз шул Союзның төрле-төрле почмакларында. Шулай булгач, безгә хәзер ни эшләргә? Алар бөтенесен ташлап үзләренең «кечкенә Ватаннарына» кайтырга тиешләрме? Андыйлар аз җыелмаячак бит. Тикмәгә генә халыкта, байлар сугышканда ялчының чәчләре калтырый, дигән сүз йөрми. Ләкин без 70 елдан бирле ялчы, батрак түгел инде. Бәлки безнең лидерларга конкрет чара күрү кирәктер. Буш сүз, халыклар арасында кирәкле-кирәксез фикерләрне тарату соң чиккә кадәр җитте бит инде. Язгы чәчү борын төбендә. Әгәр аны өзсәк бернинди кызыл сүз дә безне бәладән йолып кала алмаячак. Шуңа күрә халык аек фикергә килер һәм 17 март көнне бердәм Союзны яклап тавыш бирер дип ышанып калам.

**Н. НЯГУКОВ.**
Норлат шәһәре.

# Күпчелек «әйе» дияр

Соңгы көннәрдә агитаторлар Совет территориясендәге авыллар халкына чакыру билетлары тарату белән мәшгуль булдылар. Чакыру билеты дигәнебез үзебезнең телдә генә шулай йөртелә. Элек сайлаулар алдыннан унйортлыкларга беркетелгән агитаторлар номерлар тарата иде. 17 мартта үтәчәк референдум алдыннан аңа үзгәреш кертергә, открыткалар тапшырырга булды. Бу үз чиратында халыкны референдумга чакыру иде.

Референдумга хәзерлек чорында Иске Әлмәт авыл Советы территориясендәге авыллар гражданнары белән җыелышлар, әңгәмәләр үткәрелде. Колхозчылар белән бригада җыелышлары уздырганда да ил күләмендә оештырыла торган бу чараның асылын, сәбәпләрен аңлатып чыгышлар ясадык. Хезмәт коллективларында, җәмәгать урыннарында төрле очрашулар вакытында да халыкны кызыксындырган сорауларны читләтеп үтмәдек.

Шуны да әйтү мөһим, авыл халкы да бу политик мәсьәлә белән кызыксына хәзер: аңламаганын сорый, төпченә, үзе белгәнен чат ачык җавап бирә. Бу мәсьәләдә авылдашларыбызның фикере уртак: Союз составында калырга. Өлкәннәр, урта буыннар һәм яшьләр дә шулай диләр. Бер үк вакытта авыл хезмәтчелләре яз якынлашуын, сәяси фәлсәфә куертудан бигрәк чәчүгә хәзерлек мәсьәләләрен күтәрәләр, күп сөйләгәнче күбрәк эшләү кирәген искәртәләр.

Бу кампанияне идеологик тәэмин итү буенча да билгеле чаралар күрелде. Җәмәгать урыннарына шул хакта искәртүче чакырулар эленде. Колхозчылар тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге белән дә таныша алалар.

17 мартта тавыш бирү авыл культура йортында үтәчәк. Аны да таләп ителгәнчә җиһазларга тырыштык. Хәзер халыкның тавыш биргәнен генә көтәсе калды. Без, халык фикерен алдан белешү күрсәткәнчә, ышанабыз: зур күпчелек «әйе» дияр.

**И. ЯҺУДИНА.**

# Тату яшәргә телибез

Әлбәттә, илебездә барган вакыйгалар мине дә борчый, һәм менә 17 мартта Бөтенсоюз референдумы үткәреләчәк дигән сүзләрне ишеткәч, күңелемә җылылык иңде. Әйе, мин дә Татарстанның РСФСР составына керүенә, анда президентлык идарәсе кертүгә каршы. Без, күпмилләтле халык, бердәм яшәргә телибез. Безгә тынычлык су белән җир шикелле кирәк.

**Н. ПОПЛАВСКАЯ**
тимер юл вокзалы начальнигы.

6 нчы разрядлы эретеп ябыштыручы Минәхәт Мотыйгуллович Морадыймов «Москва» колхозындагы тырыш, булдыклы яшьләрнең берсе. Хуҗалыкта күптән түгел генә эшләсә дә ышанычлылык, сыйфат һәм дисциплина мәсьәләсендә аңа һичкайчан сүз булганы юк. Минәхәт Мотыйгуллович—авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлауда алыштыргысыз кадр хәзер.



Рәсемдә: «Москва» колхозы эретеп ябыштыручысы М. М. Морадыймов.

Н. Азизов фотосы.

# ТЫРЫШЫП ЭШЛИЛӘР

«Комбайн» колхозы сыер савучысы Әлфия Хуҗина үз карамагындагы һәр сыердан тәүлегенә уртача 9,5 килограмм сөт сава. Әкълимә Исхакова исә аңардан азга гына калыша. Аның уртача тәүлек савымы 9,3 килограмм.

**Ә. ШӘРӘФЕТДИНОВ.**

# Сәүдә, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм торак-коммуналь хуҗалык работниклары көне



Сергей Владимирович Спасов (рәсемдә) халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү буенча район производство идарәсендә мастер булып 10 елдан артык эшли инде. Шул арада ул ике тапкыр Ростов-на-Дону шәһәрендә белемен камилләштерергә өлгерде. Соңгы елларда ул төсле телевизорлар төзәтү эшендә специальләште. Бик яхшы белгеч, намуслы мастерның клиентлар арасында дәрәҗәсе зур, ә рәсеме—көнкүреш хезмәте күрсәтү район производство идарәсенең Мактау тактасында.

В. Никонорова фотосы.

## Максатлар уртак бит

Әле кайчан гына шәһәрлеләрнең бараклардан, кысан фатирлардан уңайлыклы йортларга күченүен күреп сөенә идек. Безгә дә мәшәкатьләр кимер төсле тоела иде. Әмма ялгышканбыз. Шәһәр үсә, йортлар арта барган саен, без коммуналь хуҗалык хезмәткәрләренә дә эш мәйданы киңәя, мәшәкатьләр арта тора. Хәзер безнең хуҗалык күптармаклы производство предприятиесе (МПП) дип атала һәм ул 120дән артык кешене берләштерә. Безнең карамакта мунча, кунакханә, чистарту корылмасы, урамнарны санитар чисталау һәм җыештыру, автохезмәтләр, авария-диспетчерлык службасы, теплица, торак фонд, ремонт-төзелеш участогы һәм башкалар санала.

Моңарчы күзгә артык ташланмаган коммунальник хезмәте әһәмиятен арттыра бара. Көн нәкъ безнең хезмәттән башлана да бит. Кранда су булса, чүп җыю машинасы вакытында килсә, тротуарлар-юллар чистартылган булса, кешенең иртәдән үк кәефе күтәрелә.

Бәхеткә, бездә моның мөһимлеген аңлаган кешеләр байтак. Коры чүп-чар җыюда һәр көнне график буенча эшләүче Николай Семенович Еферов һәм Анатолий Николаевич Мокин шәһәрлеләрнең ышанычын һәм хөрмәтен яулап өлгерделәр инде. Җыйнак, пөхтә итеп җыештырылган юллар, тротуарлардан атлаганда, аның өчен озак еллар бездә эшләүче Мария Прокопьевна Латышева, Анна Петровна Чеплакова, Раиса Михайловна Буракшаева, Владимир Рыбин, Анатолий Исаевка рәхмәт әйтергә кирәк. Бу—нәкъ аларның намуслы хезмәте нәтиҗәсендә салынган тәртип.

1989 елдан бирле җирле Совет йортларында бригада подряды буенча хезмәт күрсәтү оештырылган. Гамәлдәге 4 бригаданың берсе—Сәгъдиевларның гаилә подряды коллективы. Алар җаваплылыгында 150 фатир. Бу ысул белән эшли башлаганда, әлбәттә, кыенлыклар җитәрлек булды. Әмма икенче яктан, аларның үз вазифаларына намус белән каравы, йортлардагы тәртип анда эшчеләрдә зур канәгатьлек тудырды һәм бу алымның бәхәссез өстенлеген күрсәтте. Сәгъдиевлар белән дә шулай булды. 29 яшьлек бу гаилә членнары бүген хөрмәтле хезмәткәрләр, эш алдынгылары.

Яңалык һәм үсеш хезмәт күрсәтү өлкәсенә генә түгел, күптармаклы производство предприятиесенең үз эченә дә үтеп керде. Бүген предприятиенең теплицасы бар, эшчеләр ел әйләнәсенә диярлек яшел суган, кыяр, помидор белән тәэмин ителәләр. Коллектив дача участоклары бүлү турындагы карарны да зур канәгатьләнү белән кабул итте. Бүген бездә 42 кешенең шундый участогы бар, алар гаилә членнарын яшелчә белән тәэмин итә алалар. Норлат шәһәр Советы предприятие җитәкчелегенең гаражлар төзү өчен урын бирүне сорап мөрәҗәгать итүен дә канәгатьләндерде. Соңгы елларда ярдәмче хуҗалык булдыруның да файдасы күз алдында. Анда без 23 баш бозау асрыйбыз, аның ите, билгеле, инде, үз эшчеләребез өстәленә баетуга китәчәк.

Социаль-көнкүреш планында, гомумән, МПП эшчеләренә зарланырга урын юк. Көнкүреш бүлмәләре, сауна—һәммәсе бер дигән. Шулар нәтиҗәсендәдер, соңгы вакытта коллективта кадрлар алмашыну бик сизелми. Коллективның 40 процентын яшьләр тәшкил итүе дә сөенечле хәл. Яшьләр булган җирдә—энергия, һәр яңаны тизрәк кабул итү хас.

Әлбәттә, безнең тармакта да проблемалар бар һәм булачак. «Ачык хатлар көне»ндә дә безнең службага карата тәкъдимнәр, киңәшләр еш яңгырый. Без, үз чиратыбызда, әлеге тәкъдимнәрне кулланышка алып, аларны гамәлгә ашыруда шәһәрлеләрнең дә активлыгына исәп тотабыз. Безнең уңышлар нәкъ сездән, сезнең белән килешеп, уртак тел табып эшләүдән дә тора бит.

**Н. СИДОРОВА,**
күптармаклы производство предприятиесенең торак участогы мастеры.

## Бәйрәмнәр котлы булсын!

Районның халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү производство идарәсе коллективы бу юлы да үзенең профессиональ бәйрәмен сөенечле хезмәт уңышлары, куанычлар белән каршылый.

Ел саен халыкка 1,5 миллион сумлык хезмәт күрсәтелә. Шул ук вакытта производствоның күләме үсүе дәвам итә. Үсеш узган елның шушы чорында 104—108 процент тәшкил итә.

Планнарны үтәүдә районыбыздагы комплекслы кабул итү пунктларыннан Богдашкинодан Валентина Ильинична Аввакумова, Фомадан Минзатия Сәлиховна Мингалимова, Төрнәстән Нурания Исламгуловна Шәйдуллина, парикмахерлар—Раиса Лукьяновна Селуянова, Иннеса Степановна Етриванова, тегүчеләр Галина Семочкина, Наилә Вәлитова, Фәһимә Таҗиева, кисүче—Фәүзия Хаҗиморатова, шофер—Николай Сидоровның зур өлеш кертүләрен билгеләп үтәр идем.

Бу бәйрәм көнендә безнең производствода өч дистә елдан артык хезмәт куйган ветераннар А. А. Дмитриев, Н. Я. Глухов, М. Г. Кадыйров, М. Н. Казачков, Т. В. Рәфыйков, Г. М. Таһирова, Л. Е. Кабанова һәм башкаларны чын күңелдән тәбрик итәсе килә. Алар үз профессияләренә гомерләре буена тугры булып калган һәм зур чыныгу алган кешеләр. Район көнкүреш хезмәте күрсәтү производство идарәсендә эшләүче яшь буын алардан күп яктан үрнәк алсын иде.

**Р. ХӘМИДУЛЛИН,**
район производство идарәсе директоры.

## КУПШЫ СҮЗЛӘРДӘН БАШКА

Профессиональ бәйрәм—һәрвакыт имтихан ул. Торак-коммуналь хуҗалык работниклары көне дә моннан читтә калмый. Безнең хезмәт торак фондын эксплуатацияләүнең һәм торак пунктларны төзекләндерүнең сыйфатын күтәрүгә аерата игътибар бирергә тиеш, шуңа биредә уртача саннар белән дә, купшы сүзләр белән дә эш майтарып булмый. Бәяне халык бирә, аңа өйләрдә җылы барлыгы да, краннардан су килүе дә, аның тәме дә бик яхшы мәгълүм.

НГДУ торак-коммуналь хуҗалыгы коллективы зур түгел, ул 140 кешене берләштерә. Әмма аларның һәрберсе гомуми эшкә үзеннән өлеш кертә. Шулай да, профессиональ бәйрәмебезгә нинди уңышлар белән килдек соң?

Коммуналь хуҗалык балансында 93670 квадрат метр файдалы мәйдан, 56258 квадрат метр торак мәйданы исәпләнә. Алар янына 6009 квадрат метр культура-көнкүреш, склад һәм коммуналь билгеләнештәге объект керә. Капиталь ремонт үткәрү планын 1990 елда без 118,2 процент итеп, ягъни 253 мең сумлык башкарып чыктык. 14362 квадрат метр торак мәйдан ремонтланды. Агымдагы ремонт планы 125 процентка үтәлде. Планда каралган 130 мең сум урынына 140 мең сумлык түләүле хезмәт күрсәтелде. Шунысын да онытмыйк: соңгы вакытта кирпеч, пыяла, рубероид, пычкы материаллары, шифер, төрле диаметрдагы торбалар табу бер дә җиңел түгел.

Шул ук вакытта 10 мең куб метрлы чистарту корылмасының (подрядчы 53 нче СМУ) бик начар төзелүен дә билгеләргә кирәк. Гамәлдәге чистарту корылмалары гына безнең ихтыяҗны канәгатьләндерми. Без инде торак фондын җирле Советларга тапшыру өчен барлык документларны әзерләп бетердек. Эш бары махсус техникага килеп төртелде. Биредә без җирле Советлар белән уртак тел таба алмыйбыз. Техника бездә 1983 нче елдан бирле эшли, ә алар яңаларын таләп итәләр.

Бәйрәм уңаеннан коллективның уңганнары турында да берничә сүз. Иң элек сүүткәргеч канализация челтәрен караучы Анатолий Федорович Малинковны атар идем. Ике ел гына эшләсә дә үзен намуслы, яхшы эшче итеп күрсәтергә өлгерде инде, шуңа да ул берләшмәнең Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Балта остасы Юрий Тиманов, ВОС машинисты Сәмигулла Низамиевич Хәмидуллин, штукатур-буяучы Тамара Васильевна Соловьева, газ һәм электр белән эретеп ябыштыручы Владимир Николаевич Ямугин да—коллективның хөрмәтле кешеләре.

1990 ел нәтиҗәләре буенча безнең коллектив Шашин исемендәге «Татнефть» берләшмәсе коммуналь хуҗалыклары арасында беренче урынны алды һәм бүгенге профессиональ бәйрәмебез көнне безгә күчмә Кызыл байрак тапшырылачак. Бу шатлыклы вакыйга торак-коммуналь хуҗалыкны киләчәктә дә яңа уңышларга рухландырыр.

**Р. ХАҖИМОРАТОВ.**

Кешеләрне сөйгән, ихтирам иткән, аларның ихтыяҗларына колак сала белүче кеше генә сатучы булып эшли ала. «Сатучы халык хезмәтчесе», дип тикмәгә генә әйтмиләр бит. Хәзерге товарларга кытлык заманасында сатучыга бигрәк тә мөләемлык, кешеләр белән яхшы мөгамәләдә булу кирәк. Билгеле, бу нәүбәттән, сатып алучы үзе дә прилавка артындагыларны ихтирам итәргә тиеш.

Ә менә шәһәребезнең «Техника» кибете сатучылары боларның барысын да белеп эшлиләр. Товарлар тулып ятканда да һәм хәзер дә биредәге сатучылар халык ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тырышалар. Биредә аларның бригадирлары Лидия Петровна Мытированың өлеше зур. Ул 6 кешедән торган коллективның тату, дустанә эшләве өчен тырыша. Үзе дә һәрчак ачык йөзле, кешеләрнең үтенечен кире какмас өчен барысын да эшләргә омтыла. Тыйнак, ягымлы, иптәшләренә ярдәмгә килергә әзер торучы бригадирны барысы да хөрмәт итә биредә.

—Һәртөрле мактауга лаек ул,—диделәр аның турында җитәкчеләр дә.

Бригада элек тә һәм хәзер дә планнарны үтәп килә. Бүгенге көннәрдә бу җиңел бирелми, билгеле. Әмма коллектив тырыша.

Рәсемдә: «Техника» кибете бригадир-сатучысы Л. П. Мытирова.



